Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

11 декабрь 2019 ел 11 декабрь 4 номерлы

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 10 һәм 11 декабрендә гражданнар җыенының уздырылган этаплары нәтиҗәләре буенча йомгаклау протоколы төзелде:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар) тыш, 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- шул исәптән кышкы-җәйге чорда авыл эчендәге һәм урамара юлларны тәртиптә тоту;
- урам утларын карап тоту;
- Тәмте авылында балалар мәйданчыгы төзелеше;
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту ( Тәмте авылы зиратын коймалау).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 1076 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны- 551 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 551 кеше тавыш бирде;

“Юк” позициясе өчен -0 кеше

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. .”Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен чын дип таныргa.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип таныргa:
   «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар) тыш, 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:
   - шул исәптән кышкы-җәйге чорда авыл эчендәге һәм урамара юлларны тәртиптә тоту;
   -урам утларын карап тоту;
   - Тәмте авылында балалар мәйданчыгы төзелеше;
   - ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту ( Тәмте авылы зиратын коймалау).

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
   ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт ( мәдәният йорты бинасы)
   ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт
   ( административ бина)
   Шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге башлыгы: И. А. Зиновьев